«Авыл кибетләрен «бурыч кенәгәсе»ннән башка күз алдына китерүе кыен»

Эшмәкәр Рөстәм Нәҗипов Президентка меңнән азрак кеше яшәгән авыл кибетләренә онлайн-касса системасын кертмәүне сорады. Президент исә ризалашып, өч ел сынау формасында онлайн-кассаларсыз эшләп карарга тәкъдим итте.

4 БИТ

«Без бу җиргә яратырга килгән!»

Гаиләдә ничә бала булырга тиеш? Бу сорауга һәр гаилә үзенчә җавап бирә. Ә менә Аксубай районы Урмандеево авылында яшәүче Татьяна һәм Михаил Максимовлар гаиләсе «мөмкин кадәр күбрәк» ди. Әгәр дә шулай булмаса, алар үзләренең дүрт балалары янына тагын дүрт ятимне сыендырмаслар иде.

6 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 7.04.2017 | № 37 (5799)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ӘБИЛӘРГӘ НИ ҖИТМИ?!

Казанда гомер итүче 91 яшьлек Вера Филянина, рәхәтләнеп, «Сәйдәш» мәдәният сараендагы театр түгәрәгенә йөри. Аның кебек дәрт-дәрманы ташып торган өлкәннәр шактый башкалабызда.

Дамир БӘДРИЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Узган елның декабрендә «Игелекле Казан» программасы кысаларында, «Тормыш сөючеләр» («Жизнелюб») клублары челтәре оештырылган иде. Аңа башта 800 пенсионер язылган булса, тора-бара активистларның саны 2000гә җитте, – диде мэриядә узган киңәшмәдә шәһәр Башкарма комитетының мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Абзалов.

«Тормыш сөючеләр» клублары «Сәйдәш», «Залесный», «Мирный», «Юность», «Полимер», Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарайларында, Ленин исемендәге мәдәният-ял комплексында, шулай ук «Вознесенское», «Красная Горка», «Кадышево», «Северный», «Нагорный» мәдәният йортларында, шәһәрнең Үзәк китапханәсендә һәм аның 15нче филиал-китапханәсендә эшли. Өлкәннәр җыр, бию, театр түгәрәкләренә йөриләр, бакчачылык нечкәлекләрен үзләштерәләр. Рәсем түгәрәген Татарстан Рәссамнәр берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев шәхсән үзе алып бара. Казанның медицина университеты, сәнгать академиясе, мәдәният институты студентлары һәм аспирантлары тематик лекция-күнегүләр үткәрә.

Мэр Илсур Метшин исеменнән «Сәйдәш» мәдәният сараена бүләк ителгән аккордеон биредә «Жизнелюб» вокал төркеме оешуга сәбәпче булган.

Җәй башыннан, ягъни 1 июньнән «Тормыш сөючеләр» клублары әгъзалары Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркында, Урицкий исемендәге, «Крылья Советов», «Континент» паркларында, Аксенов бакчасында, Дәрвишләр бистәсендәге паркта җыелыша башлый. Анда төрле күнегүләр, скандинавия йөреше һәм хәтта көнчыгыш көрәше алымнарын өйрәнү оештырыла.

«Тормыш сөючеләр» клубына йөрүчеләрнең күңелләре һаман 18дә. Аларның «Танышулар клубы» оештырырга ниятләүләре бер дә гаҗәп түгел. Бирегә йөрүчеләрнең 80 проценты – хатын-кызлар.

Мэр Илсур Метшин да үзенең фикерләре белән уртаклашканда соклануын яшермәде.

– Барчабызга да Вера Филянина кебек 91 яшькә кадәр җитеп, җанга якын эшләр белән шөгыльләнергә язсын. Актив озын гомер – югары үсешкә ирешкән җәмгыятьнең бер билгесе ул, – диде мэр Илсур Метшин. – Казан пенсионерларының, кайсы районда яшәүләренә карап, теләк-тәкъдимнәре төрлечә булырга мөмкин. Шуңа да районнар үзенчәлеген исәпкә алырга кирәк.

Мэр Илсур Метшин әлеге клубларның бушлай булуын искәртте һәм пенсионерларны актив тормыш алып барырга чакырды.

«Тормыш сөючеләр» («Жизнелюб») клублар челтәренең телефоны: **236-42-93**. Атнаның эш көннәрендә 9.00-17.30 сәгатьләрдә хәбәрләшергә була.

Санкт-Петербург, Казан сезнең белән!

Күңелдә яз, мәхәббәт ялкыны, якты-матур хисләр. 3 апрель көнне Санкт-Петербург каласында метрода кайсысы эшкә, кайсысы укырга баручы пассажирлар да нәкъ шушы уйлар дулкынында булгандыр.

АКЦИЯ

Автор фотолары

Дамир БӘДРИЕВ

Әмма һич көтмәгәндә «Сенная площадь» белән «Технологический институт» метро станцияләрендә көчле шартлау тавышы яңгырый. Әлеге террорлык актында 11 кешенең гомере өзелде. Соңрак хастаханәдә тагын өч кеше якты дөнья белән хушлашты. Мәгълүматларга караганда, 82 кеше төрле авырлыктагы тән җәрәхәте алган, 49 кеше хастаханәгә эләккән.

Бөтенроссия халык фронтының Татарстан Республикасы төбәк бүлеге һәм Әфганстандагы сугыш инвалидлары, «Татарстан Республикасы студентлар лигасы», «Отечество» берләшмәсе», «Гражданлык җәмгыяте» иҗтимагый оешмалары башлангычында Казанда 6 апрельдә «Бергәләшеп террорчылыкка каршы» дигән сәяси акция үткәрелде.

Әфганстандагы сугыш инвалидларының Татарстан республика иҗтимагый оешмасы әйдаманы Евгений Кабыш:

– Әфганстандагы сугыш ветераны буларак, мин сугышның нинди коточкыч нәрсә икәнлеген яхшы беләм. Санкт-Петербург метросында тыныч тормыштагы халыкны шартлатып, дошман куркакларча һәм астыртын һөҗүм итте. Кешеләр үлеме – һәрберебезнең фаҗигасе, җәмгыятебез фаҗигасе рәвешендә кабул ителде. Мондый террорлык актларына юл куймаска кирәк. Бабаларыбыз һәм әтиләребез әйткәнчә, дошман уза алмас, Җиңү безнеке булыр! – диде.

«Татарстан Республикасы студентлар лигасы» яшьләр иҗтимагый оешмасы әйдаманы Элькин Искендеров:

– Татарстан студентлары Санкт-Петербургтагы терактны нәфрәтләнеп кабул итте. Гражданлык җәмгыятендә мондый фаҗигаләр булырга тиеш түгел. Террорчыларның дине дә, милләте дә, төсе дә юк, – диде.

– Ислам динендә террорлык актларына өндәү юк. Бу – имансыз кешеләр эше. Коръәндә әйтелгәнчә, бер кешене үтерү – бөтен кешелекне үтерү, ә бер кешене коткару – бөтен кешелекне коткару, – диде «Апанай» мәчете имам хатибы Нияз хәзрәт Сабиров.

Казан һәм Татарстан метрополиты Фиофан: «Аллаһ исеме белән төрле җинаятьчел гамәлләргә үгетлиләр икән, ышанмагыз. Аллаһка юл үлем, кан аша түгел, ә тынычлык һәм намус аша ирешелә», – дип, яшьләрне аңлы булырга чакырды.

Сәяси акция Татарстандагы иҗтимагый оешмаларның, татарстанлыларның Санкт-Петербург шәһәренә һәм халкына теләктәшлеге буларак яңгыраш тапты. Мөрәҗәгатьтә әйтелгәнчә, Татарстан террорлык гамәлләренә һәм радикаль адымнарга каршы. Татарстанда төрле милләт һәм дин вәкилләренең күпгасырлык дустанә мөнәсәбәт үрнәгә раслаганча, тыныч шартларда гына илнең, республиканың, туган шәһәрнең яки авылның, үзеңнең гаиләңнең киләчәге, ышанычлы нигезе бар.

Укытучыны дәүләт хезмәткәренә тиңләмәкчеләр

Россия Дәүләт Думасында укытучыларны дәүләт хезмәткәре итәргә тәкъдим иттеләр, дип яза «Бизнес-онлайн». Әлеге тәкъдимнең авторы – Дәүләт Думасы депутаты, Думаның мәгариф һәм фән комитеты әгъзасы Сергей Боженов фикеренчә, бу укытучыларның хезмәт хакын лаеклы итү мөмкинлеген бирәчәк. Хезмәт хакын төбәкнең икътисадына бәйле итү дөрес түгел, алай булганда, белем бирүнең сыйфаты да төрле төбәктә төрлечә була, дигән ул.

Түбән Кабан күле буе төзекләндерелә

Казанда Түбән Кабан күленең уң як ярында Turenscape + МАП architects Россия-Кытай консорциумы проекты эскизлары буенча эш башланды, дип яза Казан мэриясе порталы. Проект буенча 186 гектарлы Кабан күле яр буйлары мәйданнарындагы эш барышында табигать ландшафты сакланырга, шул ук вакытта шәһәр халкы өчен ял зоналары да булдырылырга тиеш.

Эскиз нигезендә 25,5 гектарда «Татинвестгражданпроект» оешмасы проект эшләрен алып бара. Сәлимҗанов урамы ягыннан күлнең уң ярында проект буенча велосипедлылар һәм җәяүлеләр юллары, Open street күңел ачу мәйданы һәм башка ял урыннары булдыру каралган.

Субайлар кагу өчен мәйдан әзер, яңгыр сулары агу урыннары тәгаенләнгән. Ярымутрау платформасы төзү өчен 35 субай кагылган. Эшләрнең беренче этабында тротуар һәм автомобиль юлларын төзекләндерү каралган. Хәзерге вакытта төп эш булып Сәлимҗанов урамын тарайту хисабына тротуарны киңәйтү, Айдинов урамына уң як борылышны торгызу һәм яр буен киңәйтү тора.

Түбән Кабан күле ярларын төзекләндерүнең беренче этабы кысаларындагы эшләрне 2017 елның икенче кварталында тәгәлләү ниятләнелә. Казанның йөзек кашы булган, зурлыгы һәм тарихи әһәмияте ягыннан да уникаль булган сулык чын мәгънәсендә үзенә тартып торачак болай булгач.

Алданган өлешчеләргә 402 фатир тапшырыла

Алданган өлешчеләр белән бәйле проблемаларны Татарстан Президенты үзе контрольдә тота. Бу мәсьәләдә, Рөстәм Миңнеханов карары белән, Татарстан премьер-министры вазифаларын вакытлыча башкаручы Алексей Песошин җитәкчелегендә даими эшли торган хөкүмәт комиссиясе төзелде.

domkaz.ru

Әлеге комиссия һәр йортка кагылышлы җитешсезлекләрне ачыклый һәм финанс чыганагы эзләү белән мәшгуль.

Шул рәвешле Казанда «Акварель» торак комплексының 5нче йорты төзелеп бетте. Алданган өлешчеләр, ниһаять, күптән хыялланган торакларына аяк басачак. Тиздән аларга 402 фатирның ачкычларын тапшырачаклар. Финанслар белән тоткарлыклар булу сәбәпле, йорт вакытында сафка басмаган иде. Аны «Свей» активларын гамәлгә кертеп төзеп бетерү мөмкин булды. Казандагы башка торакләр, Чаллыда һәм республиканың башка шәһәрләрендә проблемалы йортлар төзелешен тәгәлләү буенча максатчан һәм планлы эш алып барыла.

Тагын яллар

Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы россиялеләргә май аендагы ял көннәре турында хәбәр итә. Яз һәм хезмәт бәйрәмендә – өч (29 һәм 30 апрель, 1 май), Җиңү көне уңаеннан дүрт көн (6, 7, 8 һәм 9 май) ял итәчәкбез.

Сүз уңаеннан: Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы 2018 елга ял һәм бәйрәм көннәре графигын тәкъдим иткән иде. Аның нигезендә, киләсе елга майның беренче өлешендәге ял көннәре бер көнгә озынрак булачак, ә 2018 елның 9 маенда өстәмә ял көне көтелми.

Европага тагын бер тәрәзә ачыла

26 апрель көнне Казан һәм Рига арасында яңа авиарейс ачыла. Татарстанның Туризм комитеты җитәкчесе Сергей Иванов сүзләренчә, яңа маршрут Балтыйк буе илләре белән Татарстан халкы өчен яңа туристик мөмкинлекләр ача. Ул бизнес вәкилләре өчен дә уңайлы булачак.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Туристлар өчен иң мөһиме – логистика, аларны беренче чиратта ничек итеп тиз һәм уңайлы барып җитү мәсьәләсе борчый. Яңа авиарейс ярдәмендә безгә Латвиядән килүчеләрнең дә саны артыр дип уйлыйбыз, – диде ул Татарстан белән Латвия арасындагы туристлык юнәлешен үстерүгә багышланган матбугат очрашуында.

Россиядә һәм Бәйсез Дәүләтләр Берләгендә «AirBaltic Corporation» вәкиллеге җитәкчесе Андрей Ларченко әйтүенчә, билетларның 20 проценты инде сатылган.

– Бу без көткәннән дә күбрәк. Рейска кадәр өч атна вакыт бар әле, бу сан тагын да артыр дип торабыз, чөнки Россиядә билетларны ике атна кала алу гадәте бар, – ди ул.

Латвиянең икътисад министры киңәшчесе Ивета Струпка әйтүенчә, Латвиягә иң күп туристлар Россиядән килә. Кунакларның 13 процентын Россия кешеләре алып тора.

– Латвиядә яшәүче татар диаспорасы өчен дә ике ил арасындагы туры рейс уңайлы булачак, алар Казанга ешрак килә башлар, – диде ул.

Рейслар атнага ике тапкыр төнге сәгатьләрдә башкарылачак. Моның үз уңайлыгы бар: Ригада төшеп, аннан башка җиргә очарга теләүчеләр аэропортта озаклап утырмаячак. Ни өчен дигәндә, әлеге рейс Европага 23 төрле юнәлешне берләштерә ала. Казаннан Латвиягә очу 99 евродан башлана.

– Әлеге рейс ярдәмендә без Европага тагын бер тәрәзә ачачакбыз, – дип белдерде «Казан» халыкара аэропортының стратегик үсеш директоры Вероника Акташева. – Якын араларда Тбилисига, Кытайга, Калининградка һәм Ереванга да туры авиарейслар ачу нияте бар. Төркиягә дә даими һәм чартер рейслар артыр диган ышаныч бар.

Сүз уңаеннан: Казан май бәйрәмнәрендә балалар белән ял итәргә өстенлек бирелгән шәһәрләрнең беренче унлыгына кергән. Рейтинг 29 апрельдән 10 майга кадәр кунакханәләргә һәм апартаментларга балалар белән яшәү өчен урын алудан чыгып билгеләнгән. Май бәйрәмнәрендә балалар белән сәяхәт кылу һәм ял итү өчен – Прага, Минск, Вена, Будапешт, Тбилиси, Батуми, Баку, Таллин, Ереван һәм Вильнюс чит ил шәһәрләре арасында популяр беренче унлыкта тора. Бирегә иң арзанлы шәһәр – Вильнюс, анда бер тәүлек яшәү туристка 2,6 мең сумга төшә. «ТурСтат» агентлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 елда Россия буйлап балалар белән сәяхәт итү, узган елга караганда, 10 процентка арткан, дип яза «Татар-информ».

Казанга «ак калфаклы»лар җыела

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә, 13-15 апрельдә V Бөтендөнья татар хатын-кызлары җыенын үткәрә.

Комитетның рәис урынбасары Данис Шакиров әйтүенчә, быелгы җыенда Татарстан районнарыннан, Россиянең 67 төбәгеннән, 15 Ерак һәм Якын чит илдән 400 делегат катнашачак. Шулай ук чарага махсус чакырылган мәртәбәле кунаклар килүе дә көтелә. Җыенның форматы да ел саен үзгәртелеп торыла. Быел «Ак калфак» оешмасы шәһәр һәм район башлыклары белән берлектә әзерләнгән программа нигезендә эшли. Җыен кунаклары 13 апрельдә Арча, Биектау, Балтач һәм Яшел Үзән районнарына барачак. Биредә алар «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмаларының эшчәнлеге, халыкның тормыш-көнкүреше һәм «Бишек туе»н үткәрү тәртибе белән танышачаклар.

– Дүртенче җыенда без төп игътибарны «Бишек туй»ларына биргән идек. Шуны дәвам итү максатыннан, ике җыен арасында дүрт-биш җирдә күчмә утырышлар үткәрелә. Бишек туйларын, җырларын өйрәтү, үзебезнең киемнәргә кайту мәсьәләләре каралды. Әлеге җыенда исә «Бишек туй»лары конкурсына да йомгак ясала, – диде журналистлар белән очрашуда «Ак калфак» оешмасының җитәкчесе Кадрия Идрисова.

Җыенның икенче көнендә Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында пленар утырыш планлаштырылган. Быелгы форумның тагын бер үзенчәлеге – театр фойесында кунаклар өчен махсус фото һәм милли кул эшләре – калфаклар һәм кульяулыклар күргәзмәләре оештырылачак.

– Хатын-кызларыбызга калфаклар кияргә кирәк, дигән үтенеч белдергәч, каян алыйк соң аларны, ничек эшлик, дигән сораулар калкып чыкты. Шуннан соң, конгресс ярдәме белән, калфаклар тегү һәм изүләр эшләү дәресләрен оештырып җибәрдек. Анда төрле илләрдән, төбәкләрдән 158 хатын-кыз катнашты. Хәзер дә кайда гына нәрсә генә эшләсәк тә, осталык дәресләре үткәрәбез. Осталарыбыз Казаннан гына түгел, төрле төбәкләрдән җыела. Шуңа күрә дә быелгы җыенда менә шундый күргәзмә оештырырга булдык. Монда һәр район, һәр төбәккә генә хас калфаклар тәкъдим ителә. Кульяулык чигү осталарын да барлыйбыз, – дип аңлатты Кадрия ханым.

Шулай ук әлеге көнне гүзәл затлар Казан Ратушасының Колонналар залында узачак «Калфак туе» чарасында да катнашачаклар. Монда татар милли киемнәрен тәкъдим итүче дизайнерлар чыгышы булыр дип көтелә. Татарстан, Башкортстан, Мәскәү, Оренбург дизайнерлары төрле яшьтәге – бишектәге сабыйлар, яшүсмерләр, яшь туташлар өчен милли киемнәр тәкъдим итә.

– Бу чараны беренче тапкыр оештырганда, шактый тәнкыйть сүзләре ишетергә туры килде. Чөнки милли дигәч, күпләр фольклор киемнәрен киеп килде. Әмма мин анда әйтелгән тәнкыйтьне бик рәхәтләнеп һәм горурланып кабул иттем. Әгәр кеше бүген фольклор киеме киенеп килергә риза, аны кияргә кыенсынмый икән, димәк, бу ханым-туташлар үзебезнең милли киемебезне дә кияргә риза дигәнне аңлата. «Калфак туе» һәм «Бишек туе» безнең бренд булып китте. Башкарган эшләребез көнкүрешебезгә акрынлап кереп китә икән, бу инде эшебезнең нәтиҗәсе. Нинди генә милләт булсак та, балаларга биреләсе һәр нәрсә хатын-кыз аша үткәрелә. Әгәр шуларны өйрәтмибез икән, безнең бер эшебез дә барып чыкмаячак, – ди Кадрия Идрисова.

Ратушаның беренче катында киемнәр һәм Зифа Кадыйрованың китапларын сатып алу мөмкинлеге дә, һөнәрчеләрнең осталык дәресләре дә булачак. Форум делегатлары өчен мәдәни программа да каралган. Алар Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында күренекле татар язучысы, драматург Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел тулуга багышланган «Ефәк баулы былбыл кош» спектаклен тамаша кылачаклар.

Форумда икенче җыенга кадәр эшләнергә тиешле алшарт та кабул ителәчәк: өч яшькә кадәр бала тәрбияләү, киләчәктә күчмә утырышларда соңгы васыять, төп нигез, килен-каенана темалары күтәреләчәк. 23-24 апрельдә исә Казанда һәм Әтнәдә татар халык ашлары пешерүчеләрен өйрәтү дәресләре булачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасының бүген 465 филиалы бар. Татарстанда, Россиянең 37 төбәгендә, 17 чит илдә татар хатын-кызлары берләшмәләре эшли.

«Тоталь диктант: теркәлү башланды!»

8 апрельдә үтәчәк «Тоталь диктант – 2017» акциясендә катнашырга теләүчеләр totaldict.ru интернет-порталында теркәлә ала. Рус теленнән диктантны быел республикада 50 мәйданчыкта язачаклар. Югары уку йортлары, мәктәпләр, китапханәләрдән кала Сынлы сәнгать музее, Милли музей, Казан фәнни үзәгенең фәнни китапханәсендә, Татарстан халыклары дуслыгы йортында да үзеңнең грамоталыгыңны тикшереп булачак.

Акциянең географиясе елдан-ел киңәя бара. Ул быел дөньяның 68 илендә узачак. Рус милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары, Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы Ирина Александровская сүзләренчә, быел рус теленнән диктантны самолетта очучылар да, поездда баручылар да, троллейбус пассажирлары да язар дип көтелә.

– Мәскәүдәге бер мәйданчыкта диктантны Максим Галкин укыячак. Бездә кемнәр укыячагы әлегә сер, әмма бер-ике фамилияне атый алам. Аларның берсе – «Эфир» телеканалының «Утро» программасын алып баручысы Мария Веденеева, икенчесе – «Новости Татарстана – 24»не алып баручы Зөһрә Уразбахтина, – диде ул «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында.

Тоталь диктант 2004 елдан бирле уздырылып килә, ә бездә ул дүрт ел элек уза башлады. Анда катнашучыларның саны арта бара. Үткән елны анда республика буенча 2,5 мең кеше катнашкан. Диктантны теләге булган һәркем яза ала. Актив катнашучыларны истәлекле бүләкләр һәм рәхмәт хатлары көтә.

Дилбәр ХИСМӘТУЛЛИНА.

«Корстон» комплексында Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрлек буенча советның дүртенче киңәйтелгән утырышы узды. Очрашу гадәттәгечә, Президент Рөстәм Миңнехановның төртмәле сүзләре, киңәшләре, фикерләре белән үрелеп, җанлы барды. Чарада 300гә якын эшмәкәр катнашты. Хөкүмәт органнарының эшмәкәрләр белән турыдан-туры әңгәмә алып баруы, килеп туган четерекле мәсьәләләрне уртага салып сөйләшүе уңышлы нәтиҗәләргә китерә, дип саный катнашучылар. Ә борчыган проблемалар җитәрлек. Утырышта җиде проект төркеменең тәкъдиме каралды. Кайберләренә аерым тукталыйк.

ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

«Авыл кибетләрен «бурыч кенәгәсе»ннән башка күз алдына китерүе кыен»

Эльвира МОЗАФФАР

«БУРЫЧ КЕНӘГӘСЕ» ЗАКОНЛЫМЫНИ?

Рөстәм Нәҗипов – шәхси эшмәкәр, аның авылларда өч кибете бар. Ул, онлайн кассалар аркасында авыл кибетләре ябылырга мөмкин, дип борчыла. Быелның 1 июленнән Россиядә сәүдә өлкәсендә, интернет-кибетләрдә, туклану урыннарында, туристлык агентлыкларында, кыскасы, эшмәкәрлекнең барлык тармагында да онлайн-кассалар куллану мәҗбүри булачак. Әлеге аппарат сатылган товар турындагы мәгълүматны интернет аша онлайн режимда салым хезмәтенә тапшырып барачак. бу кассаларны сатып алу шактый кыйммәт – берсе 17-35 мең сум тора, интернет хезмәтенә тоташу, кибетчеләрне укыту өстәмә чыгымнар таләп итәчәк. Рөстәм Нәҗипов, тернәкләнеп кенә килүче эшмәкәрләр өчен бу шактый зур кыенлыклар тудырырга мөмкин, дип саный.

– Акча мәсьәләсе бер хәл, авыл җирендә элек-электән бурычка сату гадәткә кергән. «Бурыч кенәгәсе»ннән башка авыл кибетләрен күз алдына да китерүе авыр. Мондый проблемалар килеп туганда, эшмәкәрләр өчен кечкенә авылларда кибет тоту отышлы булмаячак. Нәтиҗәдә сәүдә нокталары ябылып, 70 процентка якын эшмәкәрнең сәүдә өлкәсеннән китүе, сала халкының иң кирәкле продуктларны сатып алудан да мәхрүм калуы бар, – ди ул.

Шуңа да эшмәкәр җитәкчелеккә 1000нән азрак кеше яшәгән авыл кибетләренә онлайн-касса системасын кертмәүне сорап мөрәҗәгать итте.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда 100 һәм аннан да күбрәк йорт исәпләнгән авыл җирлекләрендә барлыгы 53 модульле кибет төзеләчәген искәртеп узды. Бу сәүдә ноктaлары «Авыл кибете» максатчан программасы кысаларында салыначак. Яңа аппарат кую мәсьәләсендә, 1000нән азрак халык яшәгән авылларда өч ел сынау формасында онлайн-кассаларсыз эшләп карарга тәкъдим итте.

– Моннан әллә ни зур югалтулар булмас. Аннары эшне анализлап, бу исулны 500 кешелек авылларга карата кулланырга булыр. Сез каршы түгелсездер бит? – дип, Федераль салым хезмәтенең Татарстан идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллинга мөрәҗәгать итте.

– Юк, сезгә ничек каршы килеп булсын! – дигән җавапны ишеткәч, зал алкышларга күмелде.

Президент исә елмаеп: «Монда ике генә кеше: сез һәм прокурор. Калганнар кул чаба гына белә», – дип тә төрттерде. Аннары кинәт исенә төшкәндәй:

– «Бурыч кенәгәсе» дигәннән, элек моның өчен хөкем каралган иде. Ә хәзер бу законлаштырылганмыни? – дип сорады. Зал алкышлавына кушылып: – Юк, мин каршы түгел, сатып алучы файдасына адым ясагансыз икән, бу нормаль күренеш, – дип тә өстәде.

«ЭШЛӘГӘН КЕШЕНЕҢ КУЛЫНА ӘЛӘМ»

Эшмәкәрләргә, крестьян-фермер хуҗалыкларына үз продуктларын таныту мөмкинлеге биргән авыл хуҗалыгы ярминкәләре өлкәсендә дә проблемалар җитәрлек. Үзе дә 15 ел терлекчелек белән шөгыльләнүче Әлки районыннан Алла Петрова ярминкәләрдә үз товары дип ялганлап сыйфатсыз продуктлар тәкъдим итүче алыпсатарлар, гаделсез көндәшлек, сәүдә рәтендә урын алу өчен төнлә үк килеп чират алу һәм башка мәсьәләләр хакында сөйләде. Ул, иң мөһиме Татарстан фермерларына ярминкәләрдә катнашуда тигез хокуклар бирелсен иде, дип теләде.

Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Николай Титов әйтүенчә, нәкъ менә ярминкәләрдә катнашучыларны сайлап алу таләпләре төгәл күрсәтелгән проект инде әзерләнгән. Министрлык җитештерүчеләрнең чынлап та үз товарларын сатамы икәнен болай да тикшереп, мониторинг үткәреп тора икән. Тик ничек кенә булмасын, бу система гамәлдә булса да, чишәсе проблемалар кала бирә. Әйтик, крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчеләренә иртәнге сәгать алтыдан көндезге сәгать 12гә кадәр генә сатарга рөхсәт ителә. Имеш, сыйфатлы товарны сатып бетерү өчен бу вакыт җитәрлек. Әмма фермерлар үзләре моның белән килешми. Президентны да бу кагыйдә гаҗәпкә калдырды.

– Сәгать алтыга килүдән ни мәгънә? Кешеләрнең ярминкәгә ничәгә килгәнен беләм: сәгать тугыз, уннар да була. Сату вакытын сәгать икегә, өчкә кадәр сузарга нәрсә комачаулый? – диде ул.

Сатып алучыларның ярминкәләргә дүрттән үк килеп чират алуларын ишеткәч, «димәк, өстәмә ярминкә мәйданнары булдырырга кирәк», дип, шәһәр мэры Илсур Метшинга мөрәҗәгать итте.

– Ришвәтчелек булмасын өчен, алыпсатарларны сәүдә базарыннан алырга, ярминкә мәйданчыкларын арттырырга кирәк. Фермерның теләсә кайсы вакытта ярминкәгә килеп, үз товарын сату мөмкинлеге булсын. Бу өлкәдә «кайнар элемтә» телефоны булдырырга, төгәл регламентлар билгеләнгән документ та төзергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Камияр Байтимеровның: «Безнең 25 еллык тәҗрибәбез бар. Бер-ике ярминкә мәйданчыгын тәэкләндерүне безгә бирегез», – дигән тәкъдименә Президент:

– Эшләгән кешенең кулына әләм тоттырабыз. Илсур Рәисович, ике мәйданчык биреп карыйк, эшләп карасыннар, нәтиҗәсен күрербез, – дип, ассоциация карамагына ике сәүдә мәйданчыгын тапшырырга кушты.

Бар яктан да үрнәк, инфраструктуралары булган «киләчәк шәһәре» Иннополисны да борчый торган мәсьәләләр бар икән. «Казанские кофейни» җәмгыятенең башкаручы директоры Адел Яһудин шәһәргә эшмәкәрләрне җәлеп итү өлкәсенә тукталды.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Иннополисның башкарма комитеты Эшмәкәрләр советына шәһәрнең сервис компанияләренә керү өчен бердәй концепция булдыруны сорап мөрәҗәгать иткән.

– Шәһәрдә халык саны арта бара. Өч меңгә якынлаша. Халык, Иннополиста даруханәләр, теш дәвалау сырхауханәләре, балалар өчен күңел ачу урыннары, кибетләр күбрәк булсын, дип тели. Эшмәкәрләргә яңа төзелгән йортларның беренче катыннан квадрат метры 100 сумнан биналар тәкъдим ителә. Эшмәкәрләрне шәһәргә җәлеп итәргә кирәк. Кешеләрне ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә Иннополиста калдыру өчен, без сервисны баетырга тиеш. Иннополиста бизнес белән шөгыльләнергә була. Мин моны үз мисалымда дәлилли алам, – диде Адел.

Болардан тыш, утырышта торак булмаган биналарны яңадан планлаштыруны законлаштыру, су скважиналарын куллану, андагы суның сыйфаты, транспортта кирәгеннән артык таләпләрне киметү кебек мәсьәләләрне уртага салып сөйләштеләр.

– Кайбер темалар федераль дәрәҗәдә хәл итүне сорый. Ә республикага кагылышлы сорауларга килгәндә, монда чишеп булмаслык мәсьәләләр күрмим, – диде Рөстәм Миңнеханов йомгаклау чыгышында.

Ахырдан утырышны алып барган модератор Чаллыда танылган эшмәкәр Олег Коробченконың алып бару осталыгын мактап, рәхмәтен дә җиткерде.

МИЛЛИЯТ

Тел галимнәре:

«Кайбер сүзләрне тәрҗемә итү – кроссворд чишү кебек»

Күбебезгә, аеруча журналистларга көндәлек тормышта тәрҗемә итәргә туры килә. Шактый матбугат конференцияләре, чаралар рус телендә уза. Татарча-русча сүзлекләр бар-барын, тик күбесенең электрон варианты булмау кыенлыклар, сүзләрнең берничә вариантта тәрҗемә ителүе икеләнүләр тудыра. «Татар-информ» агентлыгы журналистлар өчен махсус проект – лабораториум башлап җибәрде. Татар журналистлары эшчәнлегендә килеп туган гомуми проблемаларны тел галимнәре белән бергә бирадә даими рәвештә хәл итәчәкләр. Беренче дәрес нәкъ менә тәрҗемәләргә багышланган иде.

Эльвира МОЗАФФАР

– Тел нормалары сүзлекләрдә, грамматикада чагылыш таба. Бу сүзлекләр, гадәттә, халыкта озак еллар яшәгән сүзләргә нигезләнеп норма, кодлар салынгач кына барлыкка килә. Ә журналист бүгенге көн материалы белән эшли. Ул җәмгыятьтәге вакыйгаларны тиз арада халыкка җиткерергә тиеш. Сүзлекләрдә булмаган төшенчәләр дә килеп чыга. Шул рәвешле журналист яңа сүз тудыра. Бу исә тәрлеләккә китерә. Безнең максат – үзебезнең әчке мөмкинлекләребездән файдаланып, телнең камиллеген, төзеклеген саклау. Элек-электән әдәби нормаларны саклау турында хыялланганнар. Әмма татар теле аерым гына яши алмый. Элек тә шулай булган, бүген дә телдә алынмалар кулланыла, – ди Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Фәнүзә Нуриева.

Аның коллегасы университетның татар теле белеме кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Гөлшат Галиуллина: «Алынмалар телне бозмый, ә менә калькалар, ягъни чит тел сүзен туган телгә турыдан-туры тәрҗемә итү телнең табигый агышын үзгәртә», – дип саный.

tatar-inform.ru

КАЙБЕР СҮЗЛӘРНЕҢ ТАТАРЧАГА ДӨРЕС ТӘРҖЕМӘЛӘРЕ

- *Госзакупка – дәүләт сатып алуы яки дәүләт заказы.*
- *Первая треть XIX века – XIX гасырның беренче утыз елы, XIX гасырның беренче утыз елларына кадәр.*
- *Исполнительное производство – башкару хезмәте, башкару эше.*
- *Ремонт боковых порезов – тәгәрмәчне ямау, тәгәрмәчнең янгын ямау.*
- *Разведать – күзәтү, тикшерү, эзләү, ачыклау.*
- *Скачать с интернета – интернеттан алу, интернеттан күчереп алу.*
- *Меня настигла какая та напасть – күңелсезлеккә очрау, бәла-казага юлыгу.*
- *Преприятие – предприятие.*
- *Министерство чрезвычайных ситуаций и гражданской обороны – Гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнарны саклау министрлыгы.*

– Соңгы арада үзенчәлекле бер момент күзәтелә. Тел эчке яктан үзгәреш кичерә, аның структурасы бозыла. Рус теленнән тәрҗемәләр калькага кайтып кала. Бу исә текстны аңлауны авырлаштыра. Моннан котылып та булмыйдыр. Шулай да татар теленең менталитетына туры килгән, халык телендә кулланыла торган сүзләрдән файдаланырга кирәк, – дип саный галимә.

Әйтик, «работа над собой» сүзтезмәсен ничек дөрес тәрҗемә итәргә? «Үз өстемдә эшлим» диярга күнегелгән. Дөрес, бу сүзтезмә төрек телендә кулланыла. Шулай да татарча яңгырамый.

– Студентларым арасында «ике ел диссертация өстендә эшлим» диючеләр бар. Аларга өстеннән төшеп эшләсәгез, файдалырак булыр иде, дим, – дип, шаяру катыш мисал китерде Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Айнур Тимерханов. – Шуңа туган телгә ятышлы итеп, «үзеңне камилләштерү, белем эстәү» дип тәрҗемә итсәң отышлырак.

«Татар-информ» агентлыгы журналистлары тел галимнәренә алдан ук кайбер сүзләрне татарчага тәрҗемә итәргә биргән. «Безнең өчен кайбер сүзләрне дөрес тәрҗемә итү кроссворд чишү кебек булды», – диләр үзләре. Һәрбер сүзне җентекләп тикшергәннән соң, татарча дөрес вариантларын да әйттеләр. «Презентация» сүзен тәрҗемә итүдәге буталчыкларга да нокта куелды.

– Гаҗәп, югыйсә, «презентация» сүзен тәкъдир итү дип тәрҗемә итү дөрес түгеллеген остазым галим Фуат Ганиев күптән раслаган иде. Бу хакта фәнни эшләре дә басылып чыкты. Кызганыч, алар бөтен журналистларга барып ирешмәгән. Презентация – латин сүзе. Рус теленә тәрҗемә итсәк, «представлять» дигәнне аңлата. Тәкъдир исә гарәп сүзе. Бер мәгънәсе – бәя бирү, икенчесе язмыш дигәнне аңлата. Татарларда тәкъдир сүзе икенче мәгънәсендә күбрәк кулланыла. Презентация вакытында без тегә яки әшне тәкъдим итәбез, шуңа дөрес тәрҗемә – тәкъдим итү яки презентация, – ди Айнур Тимерханов.

Мондый эчтәлекле, мәгълүматлы дәресләр киләсе айда да узачак, дип вәгъдә итте оештыручылар.

«Айсылу» фильмының дәвамы прокатка чыга

Бу көннәрдә Казанда «Кино вакыты» III Бөтенроссия форумы узды. Чараның ачылышы мастер-питчинг форматында иде.

Мастер-питчинг – кинопроектны тәкъдим итү, ягъни фильмның потенциалын күрсәтү дигәнне аңлата. Монда Татарстан, Башкортстан, Иркутск өлкәсе, Якутия, Алтай крае, Санкт-Петербург һәм Мәскәү кинематографистлары үз эшләрен тәкъдим итте. Өч көн дәвамында барган форумның программасы тыгыз һәм кызыклы булды – сценарийлар остаханәсе, мастер-питчинг, ягъни питчинг остаханәсе эшләде, киножурналистика дәресләре алып барылды һәм сценарийлар конкурсына йомгак ясалды. Кичә чит ил фильмнарын татар теленә тәрҗемә итү һәм тавышландыру буенча да фикер алыштылар. «Игра престолов» сериалын татар теленә профессиональ дәрәҗәдә тавышландыру белән шөгыльләнүче БЕРЕНЧЕ Studio сы вәкилләре интернеттагы татар контентыннан гына торган яңа мәйдан белән таныштырды.

– Бу чара дәүләттән түгел, ә чын күңелдән, – диде «Татаркино» дәүләт оешмасы директоры Владимир Батраков, әлеге җөмләгә берничә мәгънә салып. – Кешенең кино белән чын күңелдән шөгыльләнә башлаган чакларын күрер көнгә җиттек. Монда катнашучылар – киноның киләчәге.

Россия кинематографистлары берлегенең Яшьләр үзәге директоры Дмитрий Якунин:

– Мин моны Казанда питчинг тарихының башы дип саныйм. Әлеге чараларда сезне әйдәп баручы продюсерлар күреп алыр дип өметләнәм, – дип белдерде.

Форум ачылышында безнең республиканы Татарстан кинематографистлары берлеге рәисе, режиссерлар Илдар Ягъфәров («Байгал»), Алексей Барыкин «Айсылу 2», Илшат Рәхимбай һәм Айрат Сәмигуллин («HAVA Projects» эше), Тимур Садыйков («Братья») тәкъдим итте.

Моңа кадәр прокатта шактый уңышлы барган «Айсылу» фильмының дәвамы – «Айсылу 2» трейлеры турында да сүз булды. Фильм шунысы белән игътибарга лаек: аны танылган режиссер, кинорежиссер һәм педагог Алексей Барыкинның шәкертләре – Рөстәм Рәшитов (ул шулай ук «Тапшырылмаган хатлар» фильмының да куючы режиссеры) һәм Казан дәүләт мәдәният институты студентлары төшергән.

– «Айсылу» фильмының беренче өлеше Татарстанда бик зур кызыксыну уяткан иде. Ул көннәрдә кинотеатрларга керер өчен су буе чират тезелде. Аннан соң да безгә фильмның дәвамын күрергә теләгән тамашачылардан бик күп хатлар килде. Нәтиҗәдә, Татарстанда беренче франшиза килеп чыкты. 30 минутлык кыска метражлы фильмнан тулы метражлы фильм эшләнелде, – диде режиссер Алексей Барыкин.

Исегезгә төшерәбез, «Айсылу» фильмының беренче өлешендә сүз караңгы татар авылында әнисе белән бергә яшәп ятучы Айсылу исемле туташның язмышы турында барды. Юл һәлакәтенә эләгеп, аның аяклары имгәнгән һәм ул култык таяклары белән генә хәрәкәтләнергә мәҗбүр. Туташ бик матур итеп җырлый. Бервакыт авылга музыкаль продюсер килгәч, кызның тавышына соклана һәм: «Мин бу кыздан «йолдыз» ясыйм», – ди. Нәтиҗәдә Айсылу шәһәргә килеп, шоу-бизнес казанында кайный башлый. Юлында көнләшүчеләр, дошманнар, намуссызлар да күп очрый. Шушы авырлыкларны ул ничек ерып чыгачак, гомумән, әсәр ничек тәмамлана – монысы турында кино тәшерүчеләр сер капчыкларын чишеп бетермәделәр. Аныcын 20 апрельдә прокатка чыгачак «Айсылу 2» трейлерында күрәчәкбез.

Айсылу ролен Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт Яшь тамашачылар театры артисты Гөлназ Галимуллина башкара. Шулай ук тамашачы фильмда Татарстанның халык артистлары Венера Ганиева һәм Римма Ибраһимованы да күрәчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

ГАИЛӘ

Максимовлар: «Без бу җиргә яратырга килгән!»

Гаиләдә ничә бала булырга тиеш? Бу сорауга һәр гаилә үзенчә җавап бирә. Ә менә Аксубай районы Урмандеево авылында яшәүче Татьяна һәм Михаил Максимовлар гаиләсе «мөмкин кадәр күбрәк» ди. Әгәр дә шулай булмаса, алар үзләренең дүрт балалары янына тагын үзләре ятим, үзләре сәламәтлеккә туймаган дүрт сабыйны сыендырмаслар иде.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Татьяна белән мин тәрбиягә бала алган гаиләләрнең «Без бергә!» республика иҗтимагый оешмасы уздырган җыелышта таныштым. Дөньяның иң бәхетле кешесе төсле ул – йөзеннән беркайчан да елмаю китмәс. Хәер, шулайдыр да – бүтәннәрне бәхетле иткән кеше генә бәхеткә лаек. Сигез балаң сигез яктан: «Әни!» – дип өзелеп торганда, ничек инде бәхетле булмыйсың. Хәер, сигез генә дә түгел инде, КАИны тәмамлаган олы уллары үзе гаилә корган. Уллары Емеляга яшь ярым ди. Килен дә күпбалалы һәм тәрбиягә бала алган гаиләдән. Максимовларның ике өлкән уллары КАМАЗ төзүдә, тимерчелек заводында токарь булып эшлиләр, икесе дә бер участокта. Гаиләдә хезмәттән тәм табып үсү нәтиҗәсе инде бу. Яков сигезенче сыйныфта укый. Ә төпчекләре Аксиния балалар бакчасына йөри.

Әгәр дә Ходай биргән шушы дүрт баланы тәрбияләп аякка басты рса да, әлеге гаилә алдында баш ияргә булыр иде. Әмма эштән дә, авырлыклардан да курыкмаган игелекле гаилә язмыш тарафыннан кыерсытылган сабыйларны да үзенең җылы оясына алып, аларның күз яшьләрен елмаюга алмаштырырга карар кыла. Шулай итеп, 2008 елда алар тагын Ангелина, Саша, Вася, Дианаларны булалар. Балаларның ике олысы Нурлат шәһәрендәге гомуми белем бирү коррекция мәктәбендә укый. Аксиния, Вася һәм Дианаларны әтиләре балалар бакчасыннан алып, атнага ике тапкыр 25 чакрым ераклыктагы район үзәгендәге сәнгать мәктәбенә йөртә. Күпбалалы гаиләләрдән булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән кечкенә балалар өчен эстетик үсешне арттыру максатында, махсус сыйныф ачылган икән. Ул аларга бушлай. Максимовлар гаиләсе мәктәп директоры Галина Сорутдиновага бик рәхмәтле. Балалар анда җырларга, биергә, рәсем ясарга, пластилиннан сыннар әвәләргә өйрәнәләр.

Әлеге гаиләне чын мәгънәсендә уникаль, интернациональ дияргә була. Максимовлар үзләре чуаш, тәрбиягә алынган балалар – рус, татар, таҗик милләтеннән. Рус һәм чуаш теле гаиләдә теле дип санала.

– Балалар өч айлык чакларыннан чуаш телен аңлый, ә инде яшь ярымнан аралаша ук башлыйлар, – ди балаларының ана телен белүләренә сөенеп Татьяна Владимировна.

Балалар тәрбияләү белән күбрәк әтиләре шөгыльләнә, чөнки ул башка эштә эшләми, төп һөнәре – тәрбияче. Ә Татьяна ханым үз белгечлеге буенча хезмәт куя. Казан дәүләт мәдәният университетының китапханәләр бүлеген тәмамлаган ул. 25 ел китапханәдә эшләп, авылдашларында да, үз балаларында да китапка кечкенәдән мәхәббәт тәрбияләргә омтыла. Балаларының китаплар тотып төшкән рәсемнәре белән интернет тулган. Татьяна Владимировна үзе дә студент әле. Казан инновацияләр институтында өченче курста укый, югары белемле педагог-психолог булачак. Бу белеме балалар күңеленә юлны тагын да тизрәк табарга булышачак әле аңа.

Максимовлар гаиләсенең даны район чикләрен үтеп, күптән инде республикага таралган. Әниләре «2012 ел хатын-кызы» бәйгесендә «Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңү яулаган. Әниләренә булышырга гаиләнең олысы да, кечесе дә килгән. Гаилә ансамбле чуаш телендә җырлап, «Корстон»дагыларның күңелен яулаган. 2013 елда Пензада узган «Идел буеның уңышлы гаиләсе» беренче округ фестивалендә «Шәфкатьле йөрәк» номинациясендә дә җиңү яулаган алар.

– Безнең уңышларыбызның нигезендә чуаш теле ята, – диләр Максимовлар, ана телләрен данлап. – Кайда гына булсак та, гаилә ансамбле белән үз телебездә җырлыйбыз. Әтиебез гармунда уйный. Милли киемнәр кигән балалар бераүне дә битараф калдырмый. Балаларга да туган телебез белән горурланырга бу бер сәбәп булып тора, – диләр өлкән Максимовлар беравыздан.

2013 елда аларга Мәскәүдә тәрбиягә бала алган гаиләләрнең Бөтенроссия форумында да катнашырга туры килгән. Ә инде республика фестиваль-конкурсларында алган грамота-дипломнарын санап кына бетерерлек түгел.

Әлеге гаиләне Татарстанда гына түгел, күрше Чуашстанда да яхшы беләләр. Алар андагы ярыш-бәйгеләрдә дә катнашып, җиңү яулыйлар. Чабаксарда узган «Корымас чишмәләр» республика конкурсында балалар белән бергә аларның дәү әниләре – әтиләренең әнисе һәм әтиләренең дүрт сеңлесе ирләре белән чыгыш ясаганнар. Гаилә кирәк чагында шулай бергә җыела. Югыйсә, төрле җирдә – кем Казанда, кем Аксубайда, кайберләре Чаллыда яши. «Безне милли җыр-моң берләштерә», – диләр алар.

Президент машина бүләк иткәннән соң, бу гаиләдә кая да булса бару мәшәкатьтән күбрәк бәйрәмгә әйләнгән. Алар Казанга аквапаркка да, динозаврлар паркына да, Ратушада узган Яңа ел бәйрәмендә дә җайлы гына килеп киткәннәр. Әле үзләре генә дә түгел, районның тәрбиягә бала алган гаиләләрен дә алып барганнар.

2014 елда Казан Кремлендә Татарстан Президенты һәм аның тормыш иптәше республиканың иң яхшы гаиләләрен кабул итте. Алар анда да югалып калмаган – ансамбль белән чыгыш ясаганнар. Максимовларның максаты – кемнәргәдер күренеп, мактанып йөрү түгел, сәламәтлеккә туймаган сабыйларның да матурлык тудырырга сәләтле икәнен башкаларга да күрсәтү, аларны да бу игелекле адымны ясарга этәрү. Шөкер, районда тәрбиягә бала алган гаиләләр саны арта.

Бүген Максимовларның кайбер мәшәкатьләре артта калган инде. Балаларның барысы да диярлек физик яктан сәламәт, гаиләнең горурлыгы һәм куанычы булып үсеп киләләр. Ә бит аларны моңа кадәр беркем дә алырга теләмәгән, чөнки психик, физик кимчелекләре булган балалар булганнар.

Гаилә тагын бер зур шатлыгы белән уртаклашмый кала алмады. 2015 елда алар Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан шәхси йорт төзү өчен субсидия алган, 2016 елда өй туе уздырганнар. Хәзер бу зур гаилә җырлап-биеп күңелле итеп, бөтен уңайлыклары да булган әр-яңа йортта яшәп ята. Шул ук елны Кремльдә Президентның үз кулыннан «Лада ларгус» машинасының ачкычы да тапшырылган Максимовларга.

Алардан еш кына: «Балаларны үсеп җиткәч кая куярсыз соң?» – дип сорыйлар икән. Бу сорауны күп вакыт җавапсыз калдыра алар. Чөнки кайчандыр ятим булып та, бүген бәхетле гаиләле булган сабыйлар йөгереп килеп кочаклыйлар, куллары эшли, күзләре күрә икән, алар шуңа сөенеп туя алмыйлар. Алар бүгенге көн белән яши. Иртәгә нәрсә буласын беркем дә белми. «Әгәр дә син баланы бүген бәхетле итә аласың икән, син аны эшләргә тиеш. Без шатланырга һәм яратырга туганбыз, шуны сын яхшы беләбез», – ди Татьяна, кояштай елмаеп.

Чуаш милләтеннән булган Максимовлар Татарстанда яшәүләренә дә сөенеп туя алмыйлар. Республикабызда кечкенәме-зурмы һәр милләтнең үсеше өчен уңайлы шартлар тудырылганга, Президентка да рәхмәт кенә әйтеп торалар. Авылда яшәүнең авырлыктан бигрәк күбрәк рәхәт яклары күп булуга күптән инанганнар инде. Алар: «Балалар күбрәк булган саен, гаилә ныграк була», – диләр һәм тагын бер сабыйга җылы кочакларын ачарга торалар. Тиздән, бик тиздән тагын бер 12 яшьлек күзләре начар күрүче кыз бала әлеге гаилә назын тоеп, җырлап-биеп яши башлаячак. Аны барып күргәннәр инде, хәзер документлары әзер булганны гына көтәләр. Кыз да бу көнне түземсезлек белән көтә, ди. Бәхеткә һәркемнең хакы бар бит. Максимовлар гаиләсенең ул сабыйны да тормыштан тәм-ямь табып яшәргә өйрәтәсенә бер шигем дә юк.

МӘДӘНИЯТ

Разил Вәлиев:

«70 бераз куркытса да, «яшь» дигәне өметләндерә әле!»

Шагыйрьләр җаны яз белән аваздаш,Тукай әйтмешли, анда кыш булмый да кар яумый. Шуңа күрәдер инде, шагыйрьләрнең кышкы бураннарда дөньяга килгәннәре дә гомер бәйрәмнәрен гөрләвекләр тавышына күмеп үткәрергә тырыша. 3 апрель көнне Галиәсгар Камал театрында халык шагыйре, Габдулла Тукай бүләге лауреаты Разил Вәлиевнең иҗат кичәсе булып узды.

Залда алма төшәрлек тә урын юк иде. Бәйрәмнең беренче өлешендә Кәрим Тинчурин исемендәге театрның талантлы яшь артистлары, шигъри спектакль күрсәтеп, тамашачыны да, юбилярның үзен дә еракта калган мәхәббәтле-сөюле яшьлек елларына алып кайттылар.

Икенче өлештә халкыбызны берсеннән-берсе матур мәгънәле җырлар белән баеткан авторның җырларының талантлы яшь җырчылар тарафыннан башкарылуы Разил Валиевнең яшьлек җырчысы булуын тагын бер тапкыр күрсәтте. Җырлар котлаулар белән аралашып барды. Татарстанның ике Президентының котлауларын кабул иткәннән соң, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов юбилярның чал башына чигелгән түбәтәй кигезде, кулына Коръән белән тәсбих тоттырды. Юбилярны котларга ерак Алтайдан һәм Саха-Якутиядән кадәр каләмдәш дуслары килгән иде, алар, шундый шагыйрь тудырып үстергәне өчен, бөтен татар халкына баш иеп рәхмәт әйттеләр. Шагыйрь туган авылда 50дән артык гармунчы бар икән, дистәгә якыны талантлы якташларын котларга гармуннары белән килгәннәр, аларга авылдашлары Алмаз Хәмзин дә кушылгач, сәхнә Сабан туена әйләнде. Бәйрәмгә дәү өндәүне җырчы Ренат Ибраһимов белән Венера Ганиева куйдылар. Рәхмәт әйтергә сәхнәгә менгәч, Разил Вәлиев гадәтенчә шаяртып алды: «70 саны бераз куркытса да, «яшь» дигәне күңелне юата, карт түгел бит, яшь дигәннәр», – дип, яшьлектән китәргә җыенмавын бар халыкка кабат җиткерде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Курчак минем яраткан партнерым»

Күренекле сәнгать белгече Константин Станиславскийның «Артистның көче хезмәттә һәм талантта» дигән сүзләре бар. Әлеге гыйбарә «Әкият» курчак театрында эшләүче Татарстанның атказанган артисты Юрий Чуктиевка туры килә. Аның эшчәнлеге хакында үзе белән сөйләшеп алдык.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Юра, сиңа бәхет еш елмаямы?

– Төрле вакытлар була. Шулай да 2008 елда театрлар Сабан туенда машина алуымны һәм 2013 елда «Тантана» бүләгенә ия булуымны бәхет дими, ни дисең?

– Ярты гомерең курчаклар арасында үткән. Курчак нәрсә ул синең өчен? Партнермы, әллә эш коралымы?

– Курчак минем үзем дә, уйларым да, яраткан партнерым да ул. Без хис-тойгылар, хәрәкәт аркылы җансыз әйберне җанландырабыз. Аларга җан өреп, тамашачыга курчакларның эмоцияләрен җибәрәбез.

– Курчаклар арасында иң яратканнары да бардыр бит.

– Ренат Харисның «Кәкрүшкә» әкияте буенча эшләнгән спектакльдә Кәкрүшкә роле минем өчен бик якын булды. Башта ул бик шаян. Тормышны аңламый. Аннан соң каршылыкларны җиңеп, кешеләргә ярдәм итә. Тормышның яхшылыкларыннан да торуын аңлый башлый.

– Сез озак еллар рәссамнар Валентина һәм Александр Губскийларның курчаклары белән эшләдегез. Алардан соң яңаларына ияләшү ничек?

– Бездән киткән рәссамнарны әле дә сагынабыз, чөнки алар эшләгән курчакларның йөзләре көлеп тора иде. Режиссерыбыз Илдус Зиннуров рольләрне бүлгәндә үк, ул курчакларның һәркайсын үзебезгә охшаганнар, дип кабул итә идек.

– Курчакларны сихри көчкә дә ия, диләр бит әле.

– Без бит үзебез әкиятләрдәге сихри дә, серле дә дөньяны уйныйбыз. Ул дөнья гади генә булып күренсә дә, катлаулы. Сәхнәдә без курчаклар аша чыгарган тойгылар үзенә күрә бер сихер. Ул яхшылыкны – яманнан, акны карадан аерырга өйрәтә.

– Элек балаларга патриотлык хисләре тәрбияли торган әсәрләр өстенлек итә иде. Бүген репертуарда андый спектакльләрдән кайсын әйтә аласыз?

– Заманасына карап, балаларның да карашлары үзгәрә. Компьютер заманында төрле экспериментлар кулланып эшләргә туры килә. Ркаил Зәйдулла әсәре буенча куелган «Бүре җиләге» әнә шундыйлардан. Бүре баласының юлында очраган киртәләрне җимереп, үз туганын коткарып алып кайтуы зур батырлык икәнен балалар аңлап карый.

– Синең режиссер белемең дә бар. Үзең дә берәр спектакль куеп карарга уйламыйсыңмы?

– Әйе, мин мәдәният һәм сәнгать институтында режиссура бүлеген тәмамладым. Беренче курсны тәмамлаганда, мехчылар мәдәният сараена халык театрына йөри башладым. Артист буларак практика үттем. Укуны тәмамлаганда, безнең һәрберебезне театрларга бүлделәр. Инде унҗиде ел – курчак театрында. Театрда шулай ук режиссер ярдәмчесе дә булып эшлим. Илдус Нәсыйхович репетиция үткәргәндә, кайбер фикерләремне әйтәм. Ул сүзгә колак сала. Әлегә куркудырмы, үземнең берәр әсәрне сәхнәләштерергә тотынганым юк. Шулай да берәр спектакль куеп карыйсым килә.

– Театрның киләчәген ничек күз алдына китерәсең?

– Коллективка яшь артистлар килеп торганда, җитәкчеләребез артистлар өчен бүгенгедәй тырышса, театр яшәргә тиеш.

– Әгәр сиңа кинәт кенә һөнәреңне алыштырырга кушсалар...

– Төзелешкә китәр идем.

– Ни өчен?

– Театрда эшләгән вакытта төзелеш техникумын да тәмамладым бит әле. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигән әйтемне бик яратам мин. Ир кеше тормышта югалып калырга тиеш түгел, бөтен эшне дә белергә кирәк. Әлеге һөнәрем тормышта миңа зур ярдәмче. Әти кечкенәдән шулай өйрәтеп үстерде. Үзе янгын сүндерүче дә, автобус йөртүче дә булып эшләде.

– Кешегә талант әтиеннән дә күчүчән. Үз сәләтләреңне балаларыңда да күрмисеңме?

– Кызларым Анжела белән Диананың компьютер каршында гына утырмаганнарына сөенәм. Алар икесе дә бию түгәрәгенә йөриләр. Уңышлары да бар. Олысы шушы арада, «Весенние выкрутасы» дигән халыкара балалар һәм яшьләрнең конкурс-фестивалендә катнашып, икенче урын – лауреат исемен алды. Хореография укытучысы Гөлнара Гыймаевага рәхмәтлебез. Анжела сәхнә юлын сайларга хыяллана.

Исеме Камил, язганы камил

ФИКЕР

«Син укып кара да, әйбәт булса, безгә дә әйтерсең», – диде авылыбыз китапханәчесе Зөһрә ханым, мин биредән Камил Кәримовның «Карурманда кара песи» исемле китабын алганда. Китапханәче дә монда әле генә эшли башлады, бер елдан артык элек басылып чыгуына карамастан, бу китапны да шушы арада гына алганнар, шулай булгач, китапханәче белән китапның нилектән үзара таныш түгеллеге аңлашыладыр.

teachermagazine.com

– Моның шәплеген укыганчы ук белеп торам, чөнки Камил Кәримовның беркайчан начар әйбер язганы юк һәм, шәт, иншалла, булмас та инде, – дидем мин. – Аның белән ул студентлыгын тәмамлап килгән елдан бирле таныш мин, кулыма эләккән һәр әсәрен укып барам, монысы бушрак килеп чыккан икән дип, тәмамламыйча читкә куя торган берниен очратканым юк.

Китапны укып чыктым да, әлеге сөйләшүне искә төшерер, уйга калдым әле менә. Шушы көннәрдә генә ТНВ телеканалында филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин белән әңгәмә булды. Профессор әфәнде, бүгенге татар прозасының күренекле вәкилләрен санап үткәндә, Камил Кәримовны телгә алмады. Димәк, мин, белемем, компетентлыгым җитмәү аркасында микән, әллә субъектив карашым өстенлек иткәнгәме, Камил дусның иҗатын тиешеннән югарырак бәялим булып чыга. Ни әйтсәң дә, әдәби тормышның эчендә кайнаган галим бездән күпкә мәгълүматлырак бит инде. Шулай да бер нәрсә сагайта әле: Фоат әфәнде уңай бәяләгән прозаиклар, бер-икесеннән башкалары – рәсми яктан да танылган, республиканың югары әдәби һәм дәүләт бүләкләрен алган шәхесләр иде. Алар инде күпләрнең күз алдында, исемнәре байтакларның тел очында диярлек. Сорауга мөмкин кадәр тизрәк җавап бирергә кирәк булганда, шул «билгеләләр»не телгә алмыйча, кемне телгә алсын инде ул. Хәзерге татар прозасын төпкә җигелеп тартып баручылар турында алдан әзерләнеп, иркенләбрәк сөйләргә туры килсә, Язучылар берлегенә үзе җитәкчелек иткән чорда Фатих Хөсни исемендәге премия белән бүләкләнгән (тиеннәр генә диярлек инде, ләкин эш андамыни) Камил Кәримовны, мөгаен, читтә калдырмас иде хөрмәтле профессор. Камилнең бер генә хикәясен, әйтик, шушы китаптагы «Кышкы мәтрүшкәләр»ен генә укыган кеше дә, әгәр чак кына әдәби зәвыгы булса, язучының шундый матур сүз байлыгына, укучының күңелен нурландырырлык итеп яза белүенә сокланмый калмас иде. Соң, язучының төп вазифасы да кеше күңелләренә яктылык өстәүдер ләбаса. Чырайларыбыз караңгылана барган, тормышыбызны телеэкран, интернет «албастылары» басып килгән, мәхәббәт дигән серле төшенчәне тулаем диярлек бүтән сүз алмаштырган бу заманда, укучыны азга гына булса да кеше затының һәм кешелекнең садә чакларына кайтарырлык әдәби әсәрләр язылу бигрәк тә мөһимдер. Шуны тирән аңлаганга күрә, әнә зур талант иясе Фәүзия ханым Бәйрәмова халкыбызның фаҗигале язмышы турындагы «Каработак» романын күзләр яшьләнерлек якты ноталарда тәмамлады.

Камил Кәримов китабының өч битен дә тутырмаган «Кышкы мәтрүшкәләр»не укып чыккач та, талантлы каләм белән барлыкка китерелгән сурәт күз алдыннан югалмый. Хикәядә «мин» дип аталган үсмер малай салкын тидереп авырып ята. Аның хәлен белешергә керүчеләрнең берсе – Тәнзилә. «Батыр икән – яныма килеп, күзләрен миңа төбәде... Авырып яту оят иде бу минутта, маңгаемнан кулын алганын гына көттем дә юрган белән йөземне капладым.» Боларны укыганда, кайсы гына «малайның» шулай авырып ятасы һәм маңгаенда ниндидер бер «Тәнзилә»нең фәрештә канатыдай куллары тоясы килми икән?! Шуннан соң йөзеңне юрган белән каплап бер еласаң да үкенеч түгел. Яшьләрең бит – җанны сафландыра торган сөенеч яшьләре.

«Карурманда кара песи» язучының ике повестен һәм унҗиде хикәясен эченә алган. Песи эче түгел, шундый исемдәге китап эче турында сүз бара, әлбәттә. Песи дә реаль герой, аның турындагы хикәя исеме китап исеме белән бер. Бу әсәрнең авторында да без үсмер малай яисә кызның иң тәүге садә мәхәббәтен тургай сайравына, чишмә челтерәвенә, җәйге яңгыр исенә кушып, һәммәсен бергә кабатланмас матур җыр итеп җырлаучы Камилдән бигрәк, юмор-сатира остасы Камилне таныйбыз. Сәләтең булып укый белсәң, хикәяне тот та сүзен-сүзгә сәхнәдән укы. Петросяннарның «Смехопанорама»ларындагылар бер читтә торсын. Хикәядәге адәмзат исемнәре генә дә әллә нинди тел көрмәкләндергечләрне үз итә торган сәер гадәтле барлык татарга шелтә булып яңгырый: Энгель, Ирис, Октябрина, Мирумир, Алекс, Луара, Фердинанд, Регина, Ганс, Эльза... Исемнәренә карасаң, гап-гади татар авылы кешеләре түгел, бөтен Европа халкы тупланган диярсең. Үзебезгә калса, европалашырга көчәнүебездер инде бу. Әнә зур бер төркем җырчыларыбыз да, үзгәреп, европалашабыз дип, ничек көчәнеп җырлый башладылар, җырлары төгәлләнгәнче бер-бер хәл булмаса ярар иде, дип хәвефләнәсе инде безгә. Бер сәерлек яңаларын тудыра: хикәя каһарманы – сигезенче класска күчкән Ирис, Регина әбинең йомырка урлый торган «сальмонелла кыргыры» кара песиен карурманда адаштырып калдырырга барган җиреннән үзе адашып, шул «кара-чутыр аппагым» аркасында гына авылына исән-имин кайта.

Йә, хуш, китапның, нәкъ үзем алда уйлаганча, искиткеч шәплегенә ышандым хәзер, тик бу хакта кешеләргә ничек сөйләргә менә? «Иң гүзәл җир» хикәясендә укытучы Сабира апа ни ди әнә: «Матурлыкны әйтеп буламыни, аны күрергә кирәк».

Биредәге хикәяләрне искиткеч матур да, тәэсирле дә, җылы да итүче тәгъбирләр, сурәтләүләр, язучы Камил һәм аның геройлары гына белгән әйтемнәр шулкадәр күп, аларны сөйләп чыгу һич мөмкин түгел. «Сәфәр йөргән кеше авылына кайтып кергәч, олылайганлыгын бик тиз сизә», «Иң авыр тынлык, мөгаен, укытучы белән укучы арасындагы тынлыктыр», «Җир маен «май» диләр дә, ипигә ягып ашаган кеше юк әле», «Морҗаларыннан чыккан төтенгә карарга да оялам», «Мәликә апай, чыпчыклар көтүе очып киткән тавыш чыгарып, пырхылдап куйды», «Химия заводы поселокка таба йөгерә-йөгерә дигәндәй килә», «Аның күз карашыннан беренче класста алган «икеле»ләрең өчен дә оялырсың». Мондый матурлыклар тегә «танылганнар» әсәрләрендә дә күп түгел. Ә аларсыз гына язылган хикәя – гап-гади мәкалә инде ул.

Каһарманнарыннан садәлек тә, яктылык та бөркелеп торган мондый әсәрләрне без Камил Кәримовның «Ундүрт яшьтә» исемле беренче китабыннан да кинәнеп укыган идек. Ул үзенең яңа китабында кабат ундүрт яшенә кайткан кебек. Әмма бу хәлне әдипнең йомык түгәрәккә әйләнеп кайтуы дип кабул итәргә кирәкмәс. «Ундүрт яшьтә»дәге әсәрләре аңа караланыклары да җитәрлек булган катлаулы, каршылыклы тормышны зур романнарда реаль сурәтләү алдыннан көч җыю, күңеленә яктылык туплау өчен кирәк булгандыр. Әлеге китабында садә үсмер чагы белән кабат очрашып та, бераз талган-талчыккан җанын ял иттерергә, күңеленә пакьлек өстәргә, зуррак, катлаулырак яңа әсәрләр язу өчен көч җыярга ниятләвеедер аның. Шулай булачагына бик ышанам мин.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
Балтач районы,
Карадуган авылы.

Бөек шагыйрь андый вак-төяк алдавычлардан югары

Бу көннәрдә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар турында күп сөйләнелә. Барлык әсәрләргә тукталуны кирәк санамыйм, фәкать Җәүдәт Миңнуллин һәм Рафис Исламов тарафыннан тәкъдим ителгән Тукайга багышланган басмага карата үз фикерләремне әйтеп китүне кирәк саныйм.

Беренчедән, Тукай турындагы истәлекләр соңгы елларгача басылып килделәр, алар белән татар укучыларының күпчелеге таныш инде. Шунлыктан бу истәлекләрне бастыруда Тукай шәхесе сәхифәләре битләрендә яңалык бармы икән соң?

Икенчедән, Тукай мирасын өйрәнмичә генә, моңа хәтле басылып килгән хезмәтләрне яңадан бастырып чыгару өчен генә атаклы шагыйрьнең премиясен бирү дөрес булыр микән соң?

Өченчедән, Рафис Исламов һәм Җәүдәт Миңнуллиннарның кеше хезмәтләрен туплап чыгаруларын Тукай шәхесен күтәрүдә оригиналь күренеш дип бәяләргә мөмкинме?

Дүртенчедән, Тукай премиясен шагыйрь иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә моңарчы кыл да кыймылдатмаган кешеләргә тапшыру, моңа хәтле Тукай турындагы бер хезмәтләре дә булмаган затларның китабын алдашып чыгару чарасы гына түгелме соң бу хәл?

Кем соң моның инициаторы, аны җәмәгатьчелеккә битлеген ертып күрсәтү көн тәртибендә торучы чарадыр. Премиягә тәкъдим ителү һәр яктан нигезле булырга тиеш.

Моны җәмәгатьчелек хөкеменә тәкъдим итеп хәл итү тиештер дип саныйм.

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,
академик, профессор,
филология фәннәре докторы.

«Күбәләк» күңелле яши

ПОЧТАДАН

Арча шәһәрендә ерактан ук күренеп, балкып утырса да, безнең 11нче балалар бакчасы яңа гына салынган түгел. Әйбәтләп капиталь төзекләндерелгән генә. Бүгенге көндә бакчабызга 110 бала йөри, аларның күбесе – татар милләтеннән.

Алты балабыз – рус, бер үзбәк баласы да бездә тәрбияләнә. Төзекләнделгәннән соң яңадан ачылганга күрә, әле мәктәпкәчә әзерлек төркеменә йөрерлек яшьтәге сабыйлар юк. Аның караве, кечкенәләр төркеме быелгы уку елыннан татар төркеме итеп үзгәртелде. Балаларыбыз белән 16 педагог шөгыльләнә, санап карасаң, җиде балага бер педагог туры килә. Бу һәр бала белән якыннан торып эшләргә һәм кечкенәдән аларның сәләтләрен ачарга мөмкинлек бирә. Моның өчен әйбәтләп җиһазландырылган музыка, физкультура заллары, логопед, психолог, татар теле кабинетлары бар. Юл йөртү кагыйдәләрен өйрәтү бүлмәсе – бакчабызның горурлыгы һәм шатлыгы да. Кечкенәдән юлларда белеп, кагыйдәләрне үтәп йөрергә өйрәнгән малай-кызларыбызның киләчәге матур булыр дибез. Бакчабыз шифаханә төсле дә: анда сабыйлар сәламәтлекләрен дә ныгыта алалар, психолог белән дә аралашалар, ял итү бүлмәсендә йога элементлары ярдәмендә дөрес сулыш алырга да өйрәнәләр. Үзебезнең табигать почмагы, китапханә, хәтта тәҗрибә почмагы да бар. Соңгысын балалар аеруча ярата. Алар анда кечкенә тәҗрибәләр ясап, зур дөнья серләрен ачалар. Милләтебезгә кечкенәдән мәхәббәт уяту һәм буыннар бәйләнешен ныгыту өчен, «Әбием сандыгыннан» дигән музей почмагы да ясап куйдык. Аны тулыландыруда әти-әниләр дә, балалар үзләре дә һәрдаим ярдәм итә.

Әти-әниләр белән дә тыгыз элемтәдә торабыз. Нинди генә сораулары булса да, алар безнең янга киләләр. Бигрәк тә «Әтиләр киңәшмәсе» дигән башлангычны хуп күрәбез. Һәр төркемдә атна саен әтиләр үзләренең һөнәрләре һәм хыяллары турында сөйлиләр. Мондый очрашулардан соң балаларда кыюлык, әтиләре белән горурлык хисләре, төрле һөнәрләр турында мәгълүмат арта, бу әтиләрне дә тәрбия эшенә якынайта.

Дилә АБДУЛЛИНА,
Арча шәһәренең 11нче «Күбәләк» балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе.

Телләр дә бер, теләкләр дә

Бөтендөнья татар конгрессында Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйрьләре республикабызның каләм ияләре һәм газета-журнал хезмәткәрләре белән очрашты.

Түгәрәк өстәлнең максаты татар милләтен исән-сау саклап калу юлларын бергәләп эзләү иде. Монда төп рольне матур әдәбият, милли матбугат уйнаганын яхшы аңлаган шагыйрьләр хезмәттәшлекне арттыру һәм киңәйтү хакында килештеләр.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов Башкортстандагы милләттәшләребезгә борынгы Болгар җирләренә сәяхәт оештырырга һәм Актаныш-Илеш җирләрендә очрашулар үткәрергә вәгъдә бирде. Моны ике як та сөенеп кабул итте. Ут күршеләребез делегациясен Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстан вәкиле композитор Алик Локманов җитәкли. Кадерле кунаклар арасында Рим Идиятуллин, Халисә Мөдәрисова, Мөнир Вафин кебек өлкән һәм урта буын шагыйрьләр дә, Нурлан Ганиев төсле яшь буын вәкилләре дә бар иде. «Татар булып яшәү кайда да җиңел түгел», – диде аксакал Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рим Идиятуллин. «Бетәбез дип көтеп ятарга ярамый. Адәм баласы үләсен белсә дә, яшәргә тырыша», – диде Ркаил Зәйдулла.

Кунаклар үзләрендә Казанда нәшер ителә торган газета-журналларның бик кыйммәт булуыннан зарлансалар да, укып барырга тырышабыз, интернет сайтларыгызга керәбез, дип белдерделәр. Бигрәк тә безнең газетаның сайтын ошатуларын әйттеләр. Кунаклар Разил Вәлиевнең 70 яшьлек юбилеена багышланган бәйрәмдә да катнаштылар, кич «Казан» милли мәдәният үзәгендә Шигырь һәм җыр бәйрәме гөрләде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Хәзерге заман балалары» дип сөйләшергә яратабыз. Әлеге сүзләр, әлбәттә, күп очракта яхшы сыйфатларны күздә тотып түгел, ә ниндидер бер кимчелек буларак әйтелә. Дөрес, замана белән балалар да үзгәрә, балалар бакчасына килгәнче интернеттан үзенә кирәкле кино яки мультфильмны табып карый алган, хәтта «күп белүе» белән кайбер өлкәннәрнең дә борынына чиертерлек сабыйны бакчада нәрсә белән дә булса кызыксындыру авыр сыман. Шуңа күрә без сагаеп әйтә торган «замана баласы»н тәрбияләү сабырлык, тирән белем һәм зур көч таләп итә.

Сездә ничек? Бездә шулай...

Язучыларыбыз иҗаты, татар халкының милли бәйрәм-йолалары турында әти-әниләрнең күбесе үзе дә белми һәм нанотехнологияләр заманында яшәүче баласына алар турында белү кирәк дип тә уйламый. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр дигән бик тирән мәгънәле мәкале бар татар халкының. Әлбәттә, әти-әнидән күргәнне бала үзенә сеңдереп үсә. Хәтта тәрбия моменты булып күренмәгән гадәти яшәеш принциплары да балага алардан күчә. Тик әти-әнисе балалар бакчасына илткәннән соң башланган сабыйның «яңа тормышы» хәтта гаиләдә дә төрле коррективлар кертергә мөмкин. Чөнки бала, дөрес юнәлеш биреп тәрбияләнгәндә, хәтта ата-анасын да тәрбияләргә сәләтле.

Без үзебезнең Казан шәһәренең 50нче балалар бакчасында балаларга белем-тәрбия бирүне әти-әниләр белән бергәләп алып барырга тырышабыз. Моның нәрсәсенә шаккатасың инде, диярсез? Мәсәлән, балалар бакчасында үткәрелә торган бәйрәм һәм ачык дәресләрдә балалар үзләре генә түгел, ә әти-әниләр дә катнаша. Халкыбызның «Карга боткасы» бәйрәмен оештырганда, төп рольләрне тәрбиячеләр түгел, ә нәкъ менә әти-әниләр уйнады. Әти-әниләр арасында әлеге йоланы беренче тапкыр күреп белүчеләр дә бар иде. Иманым камил, алар әлеге бәйрәм турында хәзер мәңге онытмаячак! Чөнки аларга аны онытырга балалары мөмкинлек бирми, балачак альбомнарын актарганда, әти-әнисенә: «Хәтерлисеңме шул вакытны?» – дип, шундый күңелле бәйрәмне искә алачак.

Әниләр көнен бәйрәм иткәндә исә «Кояш гомере телим» җырын әниләр белән бергә балалар, зал уртасына чыгып, кулга-кул тотынышып җырлаганда, әниләрнең күзләрендә җемелдәгән шатлык яшьләре, аларның балачак җырын тыңлаудан ностальгия туудан гына түгел иде...

23 февральдә оештырылган бәйрәмдә балалар әти, дәү әти һәм абыйлары белән бергәләп ярышты. Гаиләдәге мөнәсәбәтләрне тагын да җылытып, буынара бәйләнешне ныгытуда мондый чараларның әһәмияте бик зур. Бакчабызда 8 Март, Яңа ел бәйрәмнәре дә әти-әниләр катнашыннан башка үтми. Шулай итеп, гадәти булып саналган чара, ачык дәресләр дә бездә Гаилә бәйрәменә әверелә.

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне алдыннан балалар белән шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында өйрәндек, шигырьләрен ятладык. Ә ял көннәренең берсендә әти-әниләр белән шагыйрьнең музей-йортына сәяхәт кылдык. Биш-алты яшьлек сабыйлар өчен мондый эксперимент бик үк урынлы түгел дип уйлаучылар да табылыр. Тик музей хатирәләре белән үрелеп, әти-әниләр һәм дәү әниләр белән бергә сәхнәләштерелгән Шигырь бәйрәме алар күңелендә эз калдырмый калмас.

Ни дисәң дә, сабый күңеленә вакытында салынган тәрбия һәм белем орлыклары вакыт узганнан соң да үз эшен башкарыр һәм кителгән җимешләрен бирер дип ышанам.

Надежда МАКСИМОВА,
Казан шәһәренең 50нче балалар бакчасы тәрбиячесе.

ОТЧЕТ о деятельности автономного учреждения
__________ГАУ РЦ Патриот____________(полное наименование учреждения) за ____2016_____ отчетный год

N п\\п	Наименование показателя деятельности	Единица измерения	2-й предшествующий год	1-й предшествующий год	Отчетный год
1.	Исполнение задания учредителя	%	100	100	100
2.	Осуществление деятельности в соответствии с обязательствами перед страховщиком по обязательному социальному страхованию	%	-	-	-
3.	Общее количество потребителей, воспользовавшихся услугами (работами) автономного учреждения, в том числе:	человек	301 588	303 365	303 582
	бесплатными, в том числе по видам услуг:	человек	301 460	303 280	303 130
	- участие в мероприятиях, утвержденных гос. заданием	человек	301 460	303 280	303 130
	частично платными, в том числе по видам услуг:	человек		-	-
		человек		-	-
	полностью платными, в том числе по видам услуг:	человек	128	85	452
	- проживание в гостинице	человек	128	85	452
4.	Средняя стоимость получения частично платных услуг для потребителей, в том числе по видам:	рублей		-	-
		рублей		-	-
4а.	Средняя стоимость получения платных услуг для потребителей, в том числе по видам:	рублей	767,0	866,0	866,0
	- проживание в гостинице	рублей	767,0	866,0	866,0
5.	Среднегодовая численность работников	человек	15	18	16
6.	Среднемесячная заработная плата работников	рублей	24,9	32,8	35,4
7.	Объем финансового обеспечения задания учредителя	тыс. рублей	17 837,1	17 528,3	16 216,8
8.	Объем финансового обеспечения развития учреждения в рамках программ, утвержденных в установленном порядке	тыс. рублей	28 970,5	24 041,0	17 520,6
9.	Объем финансового обеспечения деятельности, связанной с выполнением работ или оказанием услуг, в соответствии с обязательствами перед страховщиком по обязательному социальному страхованию	тыс. рублей	-	-	-
10.	Прибыль после налогообложения в отчетном периоде	тыс. рублей	7,9	517,4	74,4
11.	Перечень видов деятельности				
	- организация обучения граждан по военно-учетным специальностям, а также их общевойсковая подготовка; - проведение семинаров и методических сборов для специалистов по патриотическому воспитанию молодежи; - организация мероприятий физкультурно-спортивной направленности среди допризывной и призывной молодежи; - проведение военно-спортивных игр и соревнований; - организация работы военно-спортивных лагерей; - участие в разработке программно-методического обеспечения физического развития, гражданского и патриотического воспитания				
12.	Перечень разрешительных документов (с указанием номеров, даты выдачи и срока действия), на основании которых автономное учреждение осуществляет деятельность: Устав, утвержденный 21.08.2014г.				
13.	Состав Наблюдательного совета (с указанием должностей, фамилий, имен и отчеств)				
	Министр по делам молодежи и спорту Республики Татарстан Леонов Владимир Александрович Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан Шайхразиев Василь Гаязович Заместитель руководителя Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики - начальник Управления по взаимодействию с институтами гражданского общества Беляков Роман Юрьевич Заместитель министра по делам молодежи и спорту Республики Татарстан Гарифуллин Рустам Маратович Заместитель министра образования и науки Республики Татарстан Гиниатуллина Светлана Владимировна Военный Комиссар Республики Татарстан Погодин Сергей Николаевич Старший специалист 1 разряда отдела правового обеспечения кадастровых отношений Морозов Владлен Владиленович Председатель Республиканской общественной организации ветеранов (инвалидов) «Союз ветеранов Республики Татарстан» Юлашев Ахат Гайнулович Председатель Совета РОМО «Объединение «Отечество» Коноплев Александр Юрьевич Заместитель Председателя правления общественно-государственного объединения ДОСААФ Республики Татарстан Трошин Владимир Леонидович Заместитель директора ГАУ РЦ «Патриот» Нагимова Айсина Рустамовна				
14.	Иные сведения				

Главный бухгалтер Руководитель
автономного учреждения автономного учреждения
________ _Замалиева Э.Р._ ________ _Литвинов Д.К.___
Подпись Ф.И.О. Подпись Ф.И.О.
«__» _______ 20__ г. «__» _______ 20__ г.

ОТЧЕТ об использовании закрепленного за автономным учреждением имущества
_____________ГАУ РЦ Патриот____________ (полное наименование учреждения) за __2016____ отчетный год

N п\\п	Наименование показателя	Единица измерения	2-й предшествующий год		1-й предшествующий год		Отчетный год	
			на начало года	на конец года	на начало года	на конец года	на начало года	на конец года
1.	Общая балансовая стоимость имущества, в том числе:	тыс. рублей	199 914,2	200 974,7	200 974,7	201 465,2	201465,2	202225,5
	балансовая стоимость недвижимого имущества	тыс. рублей	186 210,7	186 210,7	186 210,7	186 210,7	186210,7	186210,7
	балансовая стоимость особо ценного движимого имущества	тыс. рублей	9 205,8	9 676,4	9 676,4	9 676,4	9 676,4	9 676,4
2.	Количество объектов недвижимого имущества (зданий, строений, помещений)	штук	2	2	2	2	2	2
3.	Общая площадь объектов недвижимого имущества, закрепленная за учреждением, в том числе:	кв. метров	10 262,5	10 262,5	10 262,5	10 262,5	10 262,5	10 262,5
	площадь недвижимого имущества, переданного в аренду	кв. метров	-	-	-	-	-	-
	площадь недвижимого имущества, переданного в безвозмездное пользование	кв. метров	3038,2	3038,2	3038,2	3038,2	3038,2	3038,2
4.	Иные сведения							

Главный бухгалтер Руководитель
автономного учреждения автономного учреждения
________ _Замалиева Э.Р._ ________ _Литвинов Д.К.___
Подпись Ф.И.О. Подпись Ф.И.О.
«__» _______ 200_ г. «__» _______ 200_ г.

Тарих башка, проблемалар шул ук

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында үзенчәлекле күргәзмә ачылды. Бирелә республикада булган барлык өмәләргә кагылышлы документлар тәкъдим ителә. Иң беренче рәсми өмә 1919 елның 12 апрелендә теркәлгән. Бу исә шушы вакытта җәмгыятьчелек экологик проблемаларга да күз сала башлаган дигән сүз.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Ни кызык, бер гасыр элек булган экологик проблемалар Казан өчен бүген дә актуальлеген югалтмаган. Шәһәр үзәгеннән узган Болак елгасын гына алыйк. 1890 елларда халык аннан су эчүгә карамастан, ул бик пычрак хәлдә булган. Аның экологик халәте документлар белән теркәлгән. Черек күл дә шәһәрнең иң пычрак территориясе булган. Бүген дә парк төзекләндерү өчен үз чиратын көтеп ята. XIX гасырның 70нче елларында Казанның тугыз бакчасы булган, аларны арендаларга мөмкинлек бирелгән. Шул ук вакытта шәһәр санитар табибы дигән вазифа барлыкка килгән.

– Документлар белән танышып чыккач, шундый нәтиҗәгә килдем: 60-70нче елларда халык өмәләргә бәйрәмгә барган кебек йөргән. Шәһәрне чистарту эшләре тәмамлангач, чәй эчкәннәр, концерт чаралары, музыкаль кичәләр оештырганнар. Хәзер халык аларга теләмичә генә йөри. Гомумән, кешенең экологик культурасы түбәнәйде. Әйләнә-тирәбезнең чисталыгы үзебездән тора бит, – ди Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының документларны куллану һәм саклау бүлеге баш белгече Гүзәл Ганиева.

Күргәзмә апрель ахырына кадәр дәвам итәчәк. Керү ирекле.

Алисә САБИРОВА.

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Латыповым Ниязом Диллусовичем (420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15, эл.почта s2495066@yandex.ru, тел.89270393119, квалификационный аттестат 16-12-503) выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:120305:308, расположенного: Республика Татарстан, г.Казань, с.Чебакса, ул.Школьная, д.1б, и исправлению кадастровой ошибки о местоположении границы в отношении смежного земельного участка с кадастровым номером 16:16:120305:307, расположенного: Республика Татарстан, г.Казань, с.Чебакса, ул.Школьная, д.1в.

Заказчик кадастровых работ: Храмова Наталья Николаевна (г.Казань, с.Чебакса, ул.Школьная, д.1б).

Согласование местоположения границ проводится с установлением границ земельных участков на местности путем проведения собрания, которое состоится 8 мая 2017 года в 18 часов 00 минут по адресу: РТ, г.Казань, с.Чебакса, ул.Школьная, д.1б.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г.Казань, ул.Главная, д.62/15.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 10 апреля 2017г. по 5 мая 2017г. по адресу: 420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15.

Номер кадастрового квартала, в границах которого расположены земельные участки, в отношении которого проводятся кадастровые работы, и смежные с ним земельные участки: 16:16:120305. Кадастровые номера смежных земельных участков, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:16:120305:312 (Республика Татарстан, г.Казань, с.Чебакса), 16:16:120305:83 (Республика Татарстан, г.Казань, с.Чебакса), 16:16:120305:307 (Республика Татарстан, г.Казань, с.Чебакса, ул.Школьная, д.1в).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

ООО «Земельный кадастр» в лице кадастрового инженера Усмановой Екатерины Николаевны, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность 18519; СНИЛС кадастрового инженера 116-391-061 38, РТ, г. Казань, ул. Оренбургский тракт, д. 8а, uskatya.2012@yandex.ru, 8(843)570-19-02, факс: 277-57-37, проводит работы по уточнению местоположения границы и площади земельного участка с кадастровым номером 16:50:260141:50, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, п. Константиновка, ул. Белокаменная, д. 18. Заказчиком кадастровых работ является Садыков Ильнар Равилевич, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Чуйкова, д.32, кв. 35, телефон: 89872903331.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: 420059, г. Казань, ул. Оренбургский тракт, 8а.ком. 108, в 10-00 часов 10 мая 2017г.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420059, г. Казань, ул. Оренбургский тракт, 8а, ком. 108.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 7.04.2017г. по 10.05.2017г.

Смежными земельными участками, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы уточняемого земельного участка является земельный участок с кадастровым номером: 16:50:260141:521, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г.Казань, Советский район, жилой массив Константиновка, ул. Малахитовая, д. 19а и земельный участок с кадастровым номером 16:50:260141:519, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г.Казань, Советский район, жилой массив Константиновка, ул. Белокаменная, 20.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

«ЗАО «Камдорстрой Автобаза-48» требуются водители кат. C, D, E, машинисты автокрана. Вахтовый метод, з/п сдельная.

Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 **(водители)**, 8-919-632-58-60 **(автокрановщики)**, (8552) 46-67-18.

РЕКЛАМА

Чайнворд

«Казан мәчетләре»



Нияз Бишбалта төзеде.

1. Казан шәһәренең Җ.Фәйзи урамында урнашкан мәчет.
2. Башкалабызның М.Әмир урамында урнашкан мәчет.
3. Казан шәһәренең И.Курчатов урамында урнашкан мәчет.
4. Башкалабызның Фәткуллин урамында урнашкан мәчет.
5. Казан шәһәренең К.Насыйри урамында урнашкан мәчет.
6. Башкалабызның Вяземский урамында урнашкан мәчет.
7. Казан шәһәренең Нокса урамында урнашкан мәчет.
8. Башкалабызның Газовая урамында урнашкан мәчет.
9. Казан шәһәренең Яңа Юлино урамында урнашкан мәчет.
10. Башкалабызның №7 Федераль трассасының 790 км. да урнашкан мәчет.
11. Казан шәһәренең Музыка урамында урнашкан мәчет.
12. Башкалабызның Ян тыкрыгында урнашкан мәчет.
13. Казан шәһәренең Ф.Энгельс урамында урнашкан мәчет.
14. Башкалабызның Мусин урамында урнашкан мәчет.
15. Казан шәһәренең Окольная урамында урнашкан мәчет.
16. Башкалабызның Мәскәү урамында урнашкан мәчет.

Җаваплар.
1.«Галия» **2.**«Әхтәм» **3.**«Мәдинә» **4.**«Әҗем» **5.**«Мәрҗани» **6.**«Ислам» **7.**«Мөслимә» **8.**«Әнилар» **9.**«Рамис» **10.**«Сафар» **11.**«Рафик» **12.**«Каусар» **13.**«Рәҗәб» **14.**«Болгар» **15.**«Рамазан» **16.**«Нурулла».

Вниманию руководителей промышленных и сельскохозяйственных предприятий, организаций, индивидуальных предпринимателей, других землепользователей и частных лиц!

По территории районов Республики Татарстан проходят трассы магистральных газопроводов и газопроводов-отводов высокого давления, эксплуатируемые ООО «Газпром трансгаз Казань», по которым осуществляется поставка природного газа промышленным и сельско-хозяйственным предприятиям, населению и другим категориям потребителей.

Трассы газопроводов нанесены на карты землепользования районов Республики Татарстан и непосредственно обозначены на местности опознавательными знаками.

ГАЗОПРОВОД – ИСТОЧНИК ПОВЫШЕННОЙ ОПАСНОСТИ, ВОЗНИКНОВЕНИЯ ВЗРЫВОВ И ПОЖАРОВ.

«Правилами охраны магистральных трубопроводов», утвержденными Минтопэнерго РФ 29.04.1992, Постановлением Госгортехнадзора РФ от 22.04.1992 № 9, в целях исключения возможных повреждений трубопроводов установлены **ОХРАННЫЕ ЗОНЫ** трубопроводов в виде участка земли, ограниченного условными линиями, проходящими в 25 м от оси трубопровода, с каждой стороны.

В охранных зонах трубопроводов всем лицам и организациям запрещается производить всякого рода действия, которые могут нарушить нормальную эксплуатацию трубопроводов либо привести к их повреждению, в частности:

- перемещать, засыпать и ломать опознавательные и сигнальные знаки, контрольно-измерительные пункты;
- открывать люки, калитки и двери необслуживаемых усилительных пунктов кабельной связи, ограждений узлов линейной арматуры, станций катодной и дренажной защиты, линейных и смотровых колодцев и других линейных устройств, открывать и закрывать краны и задвижки, отключать или включать средства связи, энергоснабжения и телемеханики трубопроводов;
- устраивать всякого рода свалки, выливать растворы кислот, солей и щелочей;
- разрушать берегоукрепительные сооружения, водопропускные устройства, земляные и иные сооружения (устройства), предохраняющие трубопроводы от разрушения, а прилегающую территорию и окружающую местность – от аварийного разлива транспортируемой продукции;
- бросать якоря, проходить с отданными якорями, цепями, лотами, волокушами и тралами, производить дноуглубительные и землечерпальные работы;
- разводить огонь и размещать какие-либо открытые или закрытые источники огня.

В охранных зонах трубопроводов без письменного разрешения предприятий трубопроводного транспорта запрещается:

- возводить любые постройки и сооружения;
- высаживать деревья и кустарники всех видов, складировать корма, удобрения, материалы, сено и солому, располагать коновязи, содержать скот, выделять рыбопромысловые участки, производить добычу рыбы, а также водных животных и растений, устраивать водопои, производить колку и заготовку льда;
- сооружать проезды и переезды через трассы трубопроводов, устраивать стоянки автомобильного транспорта, тракторов и механизмов, размещать сады и огороды;
- производить мелиоративные земляные работы, сооружать оросительные и осушительные системы;
- производить всякого рода открытые и подземные, горные, строительные, монтажные и взрывные работы, планировку грунта.
- производить геолого-сьемочные, геолого-разведочные, поисковые, геодезические и другие изыскательские работы, связанные с устройством скважин, шурфов и взятием проб грунта (кроме почвенных образцов).

Кроме того, сводом правил «СП 36.13330.2012. Свод правил. Магистральные трубопроводы. Актуализированная редакция СНиП 2.05.06-85*», утвержденным приказом Госстроя России от 25.12.2012 №108/ГС, установлены **ЗОНЫ МИНИМАЛЬНО ДОПУСТИМЫХ РАССТОЯНИЙ** от осей газопроводов до населенных пунктов, отдельных промышленных и сельскохозяйственных предприятий, зданий и сооружений, отдельно стоящих нежилых и подсобных строений, гаражей и открытых стоянок для транспорта, коллективных садов, автомобильных, железных дорог и других объектов. Зоны минимально допустимых расстояний определяются в зависимости от класса и диаметра газопровода, степени ответственности объектов и служат для обеспечения безопасности этих объектов.

Застройка зон минимально допустимых расстояний до газопроводов не допускается. Здания, строения и сооружения, построенные ближе установленных строительными нормами и правилами минимальных расстояний до объектов систем газоснабжения, подлежат сносу за счет средств юридических и физических лиц, допустивших нарушения.

Магистральные газопроводы и газопроводы-отводы высокого давления являются взрывопожароопасными объектами повышенного риска, их безопасность находится под постоянным контролем всех заинтересованных служб. Нарушение правил безопасности в охранной зоне и в зоне минимально допустимых расстояний газопроводов чревато серьезными последствиями. В безопасной эксплуатации объектов системы газоснабжения должны быть заинтересованы не только соответствующие службы, но и все жители Республики Татарстан.

За нарушение правил безопасности предусмотрена административная ответственность, а в случае причинения тяжкого или средней тяжести вреда здоровью человека либо в случае причинения крупного ущерба наступает уголовная ответственность.

Органы исполнительной власти и должностные лица, граждане, виновные в нарушении правил охраны магистральных газопроводов, газораспределительных сетей и других объектов систем газоснабжения, строительстве зданий, строений и сооружений без соблюдения безопасных расстояний до объектов систем газоснабжения или в их умышленном блокировании либо повреждении, иных нарушающих бесперебойную и безопасную работу объектов систем газоснабжения незаконных действиях, несут ответственность в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Перед началом строительных работ предприятия, организации или отдельные граждане, производящие эти работы, обязаны получить письменное разрешение эксплуатирующей организации на производство работ в охранной зоне и в зоне минимально допустимых расстояний газопроводов по установленной форме.

Производство работ без разрешения или по разрешению, срок действия которого истек, запрещается.

Для получения точной информации о местоположении магистральных газопроводов и газопроводов-отводов необходимо письменно обратиться в ООО «Газпром трансгаз Казань»: факс **(843) 264-57-02**, e-mail: **info@tattg.gazprom.ru**

При обнаружении утечек газа или других неисправностей на магистральных газопроводах и газопроводах-отводах просим сообщить местному органу власти, а также эксплуатирующей организации ООО «Газпром трансгаз Казань» по адресу: 420073 РТ, г.Казань, ул. Аделя Кутуя, 41, круглосуточный телефон диспетчерской службы: (843) 264-58-12 или по телефону экстренной службы: 04.

БУДЬТЕ ВНИМАТЕЛЬНЫ И ОСТОРОЖНЫ ВБЛИЗИ ТРУБОПРОВОДОВ!

Реклама

АФИША
10-16 АПРЕЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры
10 апрель «Каһым түрә» (Б.Бикбай, Х.Иргалин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
11 апрель «Ул бит кисә ине» (А.Әхмәтгалиева)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1000 сум
12 апрель «Хыялга кар-шы» (А.Баймөхәмәтов, А.Ишбулдина)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
13 апрель «Һинең мин булам кәйнәң» (С.Белов)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1000 сум
14 апрель «Антигона» (Ж.Ануй)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
15 апрель «Йосыф һәм Зөләйха» (К.Гали, Ю.Сафиуллин инсц.)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
16 апрель «Театраль тамаша»
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

11 апрель «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30
12 апрель «Төш» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30
13 апрель «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
14 апрель «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30
15 апрель «Әллә язмыш, әллә ялгыш...» (автор – Н.Нестерова, И.Хафизов тәрҗемәсе)
Башлана: 17.00
16 апрель «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев)

Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

12 апрель «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 13.00
13 апрель «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
14 апрель «По щучьему велению» (Е.Тараховская)
Башлана: 11.00, 13.00
15 апрель «Гусенок» (Н.Гернет)
Башлана: 11.00, 13.00
15 апрель «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш)
Башлана: 11.00
16 апрель «Гуси-лебеди» (инсц. Л.Кожевникова)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

12 апрель «Тамада-шоу»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1000 сум
13 апрель «Сез әле мине белмисез...» Раил Садриев
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1000 сум

«ПИРАМИДА» МӘДӘНИ-КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕ
(МӘСКӘҮ УРАМЫ, 3)

13-14 апрель «Айфара» юбилей концерты
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 600-1500 сум
15 апрель Татар музыкаль телевизион премиясен тапшыру чарасы
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 3500-5500 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

СПОРТ

ria.ru

АВТОУЗЫШ. Җәй көне Татарстан аша «Ефәк юл» ралли-рейсы үтәчәк. Автоузыш 7 июль көнне Мәскәүдә башлана. 9 июльдә узышчылар инде Казанда булачак. Иртәнге сәгать 8.30да автомобильләр Казанның Меңьеллык мәйданы, Сул як Болак, Космонавтлар урамнары аша узачак. 10.00дә исә алар Шәле авылы тирәсендәге 150 чакрымга сузылган махсус юл аша уза. «Ефәк юл» республиканың тагын берничә районы аша үтәргә тиеш.

БАСКЕТБОЛ. Бүген – 7 апрель көнне, Евролиганың 29нчы раунды кысаларында, УНИКС Миланның «ЕА7» командасы белән уйный. Матч 21.45тә башланачак.

ВОЛЕЙБОЛ. Казанның «Динамо-Академия-УОР» фарм-командасы тарихта беренче тапкыр Яшьләр лигасында алтын медаль яулады. Фарм-команда резерв команда булып санала. Гадәттә анда яшь спортчылар, төп командага күчкәнче, үз көчләрен сыный. Команда 2011 елда гына барлыкка килүгә карамастан, инде ике бакыр һәм бер көмеш медаль яулады.

8 апрель көнне Россия чемпионаты кысаларында Казан «Динамо»сы Свердлау өлкәсенең «Уралочка» командасы белән очраша. Уен Казанның «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә 18.00 сәгатьтә башлана.

КӨРӘШ. 9 апрельдә Чаллының «Витязь» спорт мәктәбендә мөселман яшьләренең Татарстан Мөселманнары дини нәзарәте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча IX турниры уза. Ярыш 18 яшьтән өлкәнрәк һәм намаз гыйбадәтен үтәүче көрәшчеләр арасында бара.

Татарча көрәш бәйгесе быел – алты, ә кул көрәше өч үлчәү категориясендә узачак. Һәр яшь категориясендә җиңүчеләргә өчәр призлы урын каралган. Аларны төрле дәрәҗәдәге дипломнар һәм 5-10 мең сум акчалата призлар көтә. Абсолют җиңүче хаҗ сәфәренә юллама алачак.

ХОККЕЙ. «Ак Барс» уенчылары капкачы Эмиль Гарипов белән һөҗүм итүче Владимир Ткачев «Еврочеллендж» матчында катнашу өчен Россиянең олимпия җыелмасына чакырылган. Алар 13-15 апрель көннәрендә Чиләбедә узачак турнирда Франция командасы белән уйнаячак.

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов:

«Суга сикерү буенча ФИНАның Дөнья сериясе ярышлары тәмамланды. Аның нәтиҗәсендә ФИНА җитәкчеләре Суга сикерү буенча дөнья сериясе этабын кабул итү буенча Казан белән төзегән контрактларын 2021 елга кадәр озынайтты. Якын киләчәктә Татарстан башкаласында ФИНА халыкара йөзү мәктәбе булдырылачак. Шулай ук Казан 2022 елда 25 метрлы аралыкта йөзү буенча дөнья чемпионатын уздыру өчен үз кандидатурасын тәкъдим итте».

Музыкантлар арасында иҗади элемтә

Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы урта махсус музыка мәктәбе «SALVE MUSICA!» дигән фестиваль үткәрә. Чаралар Казан, Чаллы, Йошкар-Ола һәм Яшел Үзән шәһәрләрендә үтәчәк.

Фестивальнең Казандагы концертлары Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында узачак. 11 апрельдә башкала тамашачысы алдында Парижда узган Халыкара конкурста гран-при яулаган, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Сергей Ферулев җитәкчелегендәге Юниор-оркестр чыгыш ясаячак. Ә 13 апрельдә узачак концертта урта махсус музыка мәктәбенең классик музыка хоралларында уйнаучылар һәм Светлана Устюгова җитәкчелегендәге хор катнаша.

Фестивальнең максаты – сәләтле балаларга ярдәм итү һәм Идел буе төбәге музыкантлары арасында иҗади элемтәләрне ныгыту.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 698. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы